ТАТАРСТАН
ВАРИСЛАРЫ

# Ак Барс кайда яши?



Рәсемгә кара, анда ничә җиләк һәм ничә күркә бар? Кошчыкларны һәм тиеннәрне дә сана.







УДК 821.512.145
ББК 84(2=632.3)6
А 41

ISBN 978-5-6043753-1-0

ТДИ ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ

Татарстан табигате мавыктыргыч формада

# Ак Барс кайда яши?

Китап Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы ярдәме белән бастырылды.

**Махсус басма**

КАЗАН
**2021**


Монда татар әкиятләре яши
tatbook.ru



## КАДЕРЛЕ ДУСТЫМ!


Син кулыңа гаҗәеп бер китап алдың. Бу — кызыксынучан Зөләйха белән аның дусты Романның әкият маҗаралары. Син бу ике дусны «Мирас Угы» анимацион фильмы аша беләсең инде. Ә хәзер син, алар белән бергә, туган ягың табигате патшалыгына сәяхәт кылырсың.

Дуслар бу юлы бар тереклекне — куе урманнарны, чәчәкле болыннарны, киң далаларны, елга-күлләрне юк итәргә теләүче явыз көчләргә каршы көрәшкә чыгалар. Геройларга хәйләкәрлек, ялган, хыянәт кебек бик күп каршылыклар аша үтәргә туры киләчәк.

Бу китапны укып чыккач, син күп нәрсәләр белерсең, туган җиреңне, аның табигатен тагын да ныграк яратырга, аны сакларга һәм якларга өйрәнерсең.







чыршы
пошш

# УРМАН ПАТШАЛЫГЫНДА

Беренче бүлектә урманда сак һәм әдәпле булырга кирәклеге ачыклана.





Роман белән Зөләйха саф һавада йөриләр иде. Кинәт көчле җил күтәрелде, кояш болытлар артына качты.

— Бу ни хәл? — дип гаҗәпләнде Роман.

Зөләйханың телефоны шалтырады.

— Зөләйха, бу Йорт иясе. Роман синең беләнме? Сез исән-иминме?

— Әйе! Нәрсә булды?

— Туган җиребезнең Саклаучысы югалды! Тизрәк музейга кайтыгыз!

Ничек югалды икән соң ул Саклаучы дип, балалар музейга ашыктылар.



— Минем күптәнге дошманнарым — Ачу белән Золым исемле явыз көчләр, Саклаучыны алдап, урлап алып киткәннәр, — диде Йорт иясе. — Алар җир йөзендәге бар тереклекне юк итәргә, урман-болыннарны кара күмергә әйләндерергә, елга-күлләрне корытырга телиләр. Аны бары тик саф йөрәкле, игелекле, уйлары пакь булган кеше генә коткара ала. Бик тиз эшләргә кирәк моны!

— Без әзер! — диделәр дуслар. — Ләкин кайдан эзләргә соң аны?

Йорт иясе балалар каршына борынгы картаны җәеп салды.

— Карта өстендә «Саклаучы» сүзен язсаң, аның кайда булганын шул ук мизгелдә күрәсең, — диде ул. — Ә билгеләнгән урынга тылсымлы каләм тидерсәң, күз ачып йомганчы шул урынга эләгәсең. Каләм бары тик яхшы кешенең кулларына гына буйсына!






— Карагыз! Карта Саклаучының урманда яшерелүен күрсәтә, — дип кычкырып җибәрде Зөләйха.

— Карта күрсәткәнчә, безгә ылыслы урманга барырга кирәк, — диде Роман.

— Ярар, балалар, хәерле юл сезгә! — диде Йорт иясе, аларны кочаклап.


тукран
дала лачыны
шәүлегән

— Бигрәк матур монда! — диде Роман, як-ягына карап.

— Әкияттәге кебек! — дип җавап бирде Зөләйха. — Кара әле, Роман, агач куышыннан тукран карап тора. Син тәрәзәдән караган кебек бу.

— Әнә, керпе йөри. Аның бик мөһим эшләре бар, ахрысы. Нәкъ синең шикелле, шундый эшлекле һәм җитди, — дип елмайды Роман.

— Урман — безнең яшел дустыбыз! Шуңа да ул, юмартлык күрсәтеп, үз байлыкларын безнең белән дә уртаклаша.

— Без Саклаучыны урлаган Золым белән Ачуны эзлибез, — диде Роман, урман җәнлекләренә мөрәҗәгать итеп.

— Без күрдек аларны! — дип сөйли башладылар җәнлекләр, берсен-берсе бүлдереп. — Алар барлык чәчәкләрне агулы гөмбәләргә әйләндерделәр, ләкин Зирәк Елга каракошы аларның сихерен юкка чыгарды. Моның өчен Золым аның канатын сындырды.

— Хәзер кайда соң алар? — дип сорады Зөләйха, борчылып.



Кызыксынучан Роман вакытын бушка уздырмады. Ул зур кырмыска оясын күреп алды һәм аны тикшерергә тотынды. Бу оя күпкатлы бер йортка охшап тора иде.

— Чын шәһәр бит бу! — дип сызгырып куйды Роман. — Ничек кызык корылган! — дип, ул җирдән ботак алды һәм кырмыска оясына төртте.




кырмыска
кырмыска оясы



— Сак бул, Ромка!

Ләкин соң иде шул — Роман кырмыскага әйләнде.


— Эх, Рома, нәрсә эшләдең инде!

— Синең дустың сихерләнде, — диде агач ботагындагы Дала лачыны. — Урманда, хәтта тылсымлысында да, бик сак булырга кирәк. Үсемлекләргә һәм хайваннарга зыян китерергә ярамый. Роман үз кызыксынучанлыгы аркасында, бу турыда онытып, бәлага юлыкты.

— Без кырмыска оясын төзәтербез, бәлки безне кырмыскалар гафу итәрләр, — дип сулкылдап куйды Зөләйха. Һәм шунда ук алар Роман белән эшкә керештеләр.

— Булдырдыгыз, балалар! — диде Дала лачыны, эш тәмамлангач. — Мин хәзер сезне Зирәк Елга каракошы янына алып барырмын. Ул ярдәм итәчәк сезгә!

Зөләйха, бер дә курыкмыйча, Дала лачыны артыннан тылсымлы урман чытырманлыгына кереп китте.







Зирәк Елга каракошы биек наратның иң зур ботагында утыра иде.

— Исәнмесез, Зирәк Елга каракошы, — дип, әдәп белән исәнләште Зөләйха. — Без дустым белән Саклаучыны эзлибез. Аны явыз сихерчеләр урлады. Ләкин минем дустым... — Зөләйха күз карашын яшерде. Аңа оят иде, күзеннән яшь тамчысы тәгәрәп төште.

— Беләм, беләм, — диде Зирәк Елга каракошы. — Синең дустың начарлык эшләде, шулай да мин сезгә ярдәм итәрмен. Биек Чатыр Тау янына барыгыз. Анда, дала уртасында, җир астыннан бәреп чыккан тылсымлы чишмә бар. Ул Романны элекке хәленә кайтарыр.

— Юлны ничек табармын соң?
— Мине үзең белән ал, Зөләйха. Мин сиңа юл күрсәтермен.
Һәм дуслар далага, кодрәтле тау ягына юнәлделәр.




сары сиртмәкойрык

# ТЫЛСЫМЛЫ ЧИШМӘ


Икенче бүлектә далада яшәүче хайваннар геройларга хаталарын төзәтергә булышалар.




тургай

Азмы-күпме барганнан соң, Зөләйха, кырмыска-Роман һәм Зирәк Елга каракошы далага килеп чыктылар. Кайсы якка карама, бар җиргә гаҗәеп матур келәмдәй үлән түшәлгән. Дусларның баш очында, аларны сәламләп, чут-чут итеп кошлар сайрый.

Ниһаять, алар биек тау янына килеп җиттеләр.




— Менә ул — Чатыр Тау! — диде Зөләйха, хәйран калып.

— Тылсымлы чишмәне кайдан табарга соң? — дип чыелдады кырмыска-Роман.

— Минем ярдәмчеләрем булышыр безгә, — диде Зирәк Елга каракошы һәм көчле аваз салды. Шулвакыт алар янына һәр яктан дала кошлары очып килә башлады.

— Сине һәм дусларыңны далада сәламләвебезгә мин бик шат, Зирәк Елга каракошы! — дип баш иде Соры көртлек.

— Рәхим итегез, — дип сәламләде аларны Бытбылдык.

— Без Урман патшалыгыннан тылсымлы чишмә эзләп килдек. Аның шифалы суы ялгыш кырмыскага әйләнгән малайны коткарырга ярдәм итә ала, — диде аларга Зирәк Елга каракошы.



— Ләкин чишмә намуслы һәм мәрхәмәтле кешеләргә генә булыша бит, — диде Бытбылдык.

— Мин бик үкенәм, — дип авыр сулап куйды кырмыска-Роман. — Мин башка беркайчан да табигатьне рәнҗетмәм.



— Мин шат, Роман, син барысын да аңладың, — дип елмайды Зирәк Елга каракошы.

— Яхшы, мин сезне Байбак янына алып барам, ул тылсымлы чишмәгә бара белә, — диде Сары Сиртмәкойрык.

Һәм дуслар кош артыннан киттеләр.

— Болар нинди оялар? — дип сорады Зөләйха.






— Син бик күзәтүчән, — дип мактады аны Сары Сиртмәкойрык. — Бу байбак оялары. Әйләнә-тирәдә үләннең азрак булганын күрәсеңме? Байбак, куркыныч янаганын үз вакытында күрү өчен, ачык урыннарны ярата.

— Шуның кадәр оя нигә кирәк аңа?

— Байбакның гаиләсе зур, балалары күп. Ул бик кайгыртучан әти.

Кинәт алар багана сыман басып торган җәнлекне күрделәр.

— Фью-фью, — дип сәламләде җәнлек дусларын.

— Исәнме, Байбак! — диде Сары Сиртмәкойрык. — Син безгә ярдәм итә, бу кызга тылсымлы чишмәне күрсәтә алмассыңмы? Аңа дустының сихерен кире кайтарырга һәм Зирәк Елга каракошын дәваларга кирәк.

— Ярый, булышырмын, — дип, эшлекле генә итеп җавап бирде Байбак.







Дуслар Байбак белән бергә юлга чыктылар һәм тиз арада тере сулы чишмәгә килеп тә җиттеләр.

Роман, чишмә суына орынуга, кешегә әверелде.

Зөләйха шифалы су белән Елга каракошының канатын чылатты. Елга каракошы сәламәтләнде.

— Сезне авыр юл көтә. Минем каурыемны алыгыз. Авыр минутта ул сезгә ярдәм итәр, — диде Елга каракошы.




— Рәхмәт, Зирәк Елга каракошы, — диделәр аңа дуслар.

Роман каурыйны букчасына яшерде һәм, картаны ачып, каләм белән анда «Саклаучы» дигән сүзне язды.

— Карта Саклаучының болында булуын күрсәтә.

— Киттек!

Балалар тылсымлы каләмне картага куйдылар.


балтырган

# КОМ ТОЗАГЫ ҺӘМ ЕЛГА КАРАКОШЫ КАУРЫЕ

Өченче бүлектә геройлар Ачу белән Золымны куып тоталар һәм тылсымлы җиләк ашыйлар.




куян



— Кеше булу рәхәт, — диде Роман, чәчәкләр иснәп.

— Нидер булган монда, — дип кашларын җыерды Зөләйха, ком өемнәренә карап.

— Ачу белән Золым болынны ком белән күмәргә, безне юк итәргә телиләр, — диде күңеле төшкән Йомран.

— Без моңа юл куймабыз! — дип кычкырып җибәрде Роман.




— Болын — күп җәнлекләрнең туган йорты, йомран өчен дә, ас, кәлтә өчен дә, — диде Зөләйха. — Шулай ук кешеләр инде күптәннән дәвалану өчен куллана торган үсемлекләр күп биредә. Аларны дару үләннәре дип атыйлар.

— Без Ачу белән Золымны эзлибез, алар Саклаучыны урладылар! — дип җәнлекләргә дәште Роман.

— Елгыр Кәлтәне чакырыгыз. Аның булмаган җире юк, һәм ул барысын да белә, — диде Йомран.





— Кем чакырды мине? — дип, үлән арасыннан Кәлтә сикереп чыкты. — Ул яман сихерчеләрне күрдем мин. Алар Саклаучыны кара ташлар тирәсенәрәк яшерделәр.

— Тизрәк шунда барыйк! — дип кычкырып җибәрделәр Роман белән Зөләйха.

— Әнә алар, — дип пышылдады Роман. — Аларны урап алырга кирәк.

Кәлтә Ачуның игътибарын үзенә җәлеп итеп торган арада, Роман белән Зөләйха Ачуга ташландылар.

— Ай-ай! Золым, коткар мине! — дип кычкырды Ачу.

— Менә тагын! — дип ысылдады сихерче. — Үзең кара шунда. Бу әшәке балалар бүтән минем күземә күренмәсеннәр.



Ярсуыннан Ачу бөтерчек кебек бөтерелә башлады. Көчле җил чыкты, ком бураны күтәрелде, дуслар төрле якка барып төштеләр.

Ком коелды да коелды, алар билдән комга күмелделәр. Роман чын егетләрчә кыю көрәшсә дә, торган саен ныграк бата барды.





Зөләйха Кәлтәгә кычкырды:

— Романның букчасыннан Елга каракошы каурыен алырга тырыш! Җитез Кәлтә ком эченә кереп китте һәм, каурыйны алып, атылып чыкты.

Зөләйха, бар көчен туплап, каурыйны Ачуга ыргытты.



Комлы дала яңадан аллы-гөлле болынга әйләнде. Үләннәр яшелләнде, чәчәк атты, кошлар сайрый башлады.

Елга каракошы каурые тигәч, Ачу, коточкыч итеп улый-улый, агулы юан балтырганга әверелде.



— Без явыз сихерчене җиңдек! Болыннарыбыз тагын чәчәккә күмелде! — дип шатланышты җәнлекләр.

— Тик без Золымны эләктерә алмадык. Ул тагын качты, — дип зарланды Роман.

— Борчылма, Рома. Әйдә, Саклаучы хәзер кайда икән, карыйк әле.

Роман, картаны ачып, тиешле сүзне язды. Тик картада бернәрсә дә күренмәде.




— Тагын язып кара, — диде Зөләйха. Карта бу юлы да җавап бирмәде.

— Аңлашылды, сихерче Саклаучыны җир астына яшергән. Шуңа күрә карта безгә берни күрсәтми, — диде Зөләйха, сәер хәлнең серенә төшенеп.




— Минем дустым Сукыр Тычкан сезне җир асты юлыннан алып барыр! — дип шатланды Йомран.

— Мин каршы түгел, тик сез бик зур һәм анда сыймассыз, — диде Сукыр Тычкан.

Җитез Кәлтә тиз генә үләннәр арасына кереп китте һәм аннан җиләкләр алып чыкты.

— Тылсымлы җиләкләр бу. Аларны ашасагыз, минем хәтле генә булырсыз. Тик кояш чыккач, сез элекке хәлегезгә кайтачаксыз.

— Минем тагын бер мәртәбә кичерәясем килми дә бит, башка чара юк, — дип авыр сулап, Роман җиләкне авызына капты.

— Ә хәзер минем арттан сикерегез, — диде Сукыр Тычкан.

Роман белән Зөләйха, Йомран белән Кәлтәгә рәхмәт яудырып, Сукыр Тычкан оясына кереп киттеләр.





# УТЛЫ ТОЗАКТА

Дүртенче бүлектә геройлар ерып чыга алмастай авыр хәлгә тарыйлар.



Зөләйха белән Роман борма-борма җир асты юллары буйлап тыныч кына Сукыр Тычкан артыннан баралар иде.

— Туктагыз, — диде ул кисәк кенә, һәм дуслар аяк астында бик зур ярык күрделәр. — Безгә шунда төшәргә кирәк.



— Сәяхәттә иң кирәкле әйбер — бау, — диде Роман, букчасын ачып.

Аска төшкәч, балалар үзләренең зур тау куышлыгында булуларын аңладылар.

— Нинди ис килә монда? — дип иснәнде Роман.





— Кайдадыр якында гына нефть — файдалы казылма бар, аны «кара алтын» дип тә атыйлар, — дип җавап бирде Зөләйха. — Нефтьтән бензин, буяу, кием-салым һәм башка бик күп әйберләр ясыйлар.

— Син шундый кызык — битең буялган, — дип елмайды Роман.



— Синеке дә, — дип көлеп җибәрде Зөләйха. — Без күмергә буялганбыз. Ташкүмер дә файдалы казылма. Ул — табигый ягулык, йортларны җылыту өчен кирәк.

— Әнә ул! — дип кычкырды Роман.

Золым, дусларны күргәч, йөгерә-кача башлады. Зөләйха белән Роман аны куа киттеләр.

— Тукта, Золым! — дип туктап калды Зөләйха. — Монда качарга урын юк сиңа!

— Бу тагын сезме, әшәке балалар. Сез Саклаучыны таба алмаячаксыз. Бу җирдә барыбер мин хакимлек итәчәкмен. Ләкин иң элек сезне юкка чыгарам!





Шушы сүзләрне әйтеп, ул путасын чиште һәм аны Роман белән Зөләйха алдына ташлады. Дусларның юлын бүлеп, ут дивары калкып чыкты.

— Ха-ха-ха! Я, нәрсә? Кем җиңде? — дип, явызларча шаркылдап көлде сихерче.


Елга

Золым тагын качып китте. Роман белән Зөләйха, якынайганнан-якыная баручы ялкын телләреннән сакланып, ут тоткынлыгыннан чыгарга тырыштылар.

— Нидер уйлап табарга кирәк! — дип кычкырды Зөләйха.

Шунда ул Романның карта белән тылсымлы каләм салынган букчасын күреп алды.



— Тылсымлы каләм белән суга бәйле берәр сүз язарга тырышып кара әле, — дип кычкырып җибәрде Зөләйха.

Роман букчасына ташланды, аннан тылсымлы каләмне алып, һавада «елга» дип язды.



Шул ук мизгелдә каяндыр җир астыннан чыккан елга агымы утны сүндерде һәм дусларны үзенә бөтереп алды.

— Рома, картаны коткар! — дип кычкырды Зөләйха.

Көтмәгәндә ул үзенең үсә башлавын тойды.



— Җиләкнең тәэсир итү көче бетә бугай, — дип кычкырды Роман. Ул да элеккеге халәтенә кайтты.

Елга дусларны тау куышы буйлап шактый гына агызганнан соң өскә чыгарды.





# Золымның сере

Бишенче бүлектә карта һәм тылсымлы каләм сихерче кулына эләгә.


— Менә бу маҗара, ичмаса! — диде Роман, комнан торып.

Дуслар тирә-юньне караштырдылар. Җир асты елгасы аларны киң күл ярына чыгарган икән.

— Нинди матур чәчәкләр!



— Төнбоеклар бу, — диде Зөләйха. — Алар гади чәчәкләргә охшамаганнар. Төнбоек суда гына үсә. Иртән иртүк ул су төбеннән күтәрелә һәм ачыла, ә кичен, таҗларын ябып, суга кереп кача.





— Каян барысын да беләсең син? — дип елмайды Роман.

— Мин бит китап укырга яратам, — дип җавап бирде Зөләйха.

— Тот аны! — дип кычкырып җибәрде Роман кинәт кенә.

Урланган букчаны күтәргән сихерче күлгә таба чаба иде. Ул, тиз генә көймәгә утырып, барлык көченә ишә башлады:

— Ниһаять, мин бу җир белән идарә итәчәкмен! — дип шатланды ул.

— Золым карта белән тылсымлы каләмне урлады! — Роман, сулышы кабып, күл читендә туктап калды.




— Саклаучыны коткарыр өчен вакыт та күп калмады бит инде, — диде Зөләйха, хәвефләнеп. — Ничек куып тотарга соң бу сихерчене?

Романның артында «кхе-кхе» дигән тавыш ишетелде.

— Сез Саклаучыны коткарырга телисез икән. Мин — Кондыз. Золымны куып җитәр өчен, сал ясарга кирәк.



— Бик яхшы фикер! — дип куаныштылар балалар.
Сал ясарга булышырга дип кошлар, тузбаш, хәтта кара елан да килде.



Салны ясап бетерүгә үк, Роман белән Зөләйха сихерчене куа киттеләр. Балыклар салны тартып барганга күрә, дуслар аны бик тиз куып җиттеләр.





Золым, салдагы балаларны күргәч, куркып калды. Тылсымлы каләмне эләктереп, «давыл» сүзен язды. Ләкин шул ук мизгелдә аның көймәсе капланды. Убырлы карчык балаларны һәлак итәргә теләде, ләкин ул каләмнең мәрхәмәтле кешеләргә генә ярдәм иткәнен белми иде шул.

Балалар суда тыпырчынган сихерче янына йөзеп килделәр.

— Кулыңны бир! — дип кычкырды аңа Роман.

Ләкин ул тыпырчынуын дәвам итте. Роман тиз генә күлгә сикерде һәм Золымга салга менәргә булышты.




Сихерче салкыннан дерелди иде, Зөләйха аңа курткасын япты.

— Нигә сез мине коткардыгыз? — дип сорады Золым.

— Бәлагә тарыганнарны ташлап китмиләр бит инде, — дип җавап бирделәр Роман белән Зөләйха.




тиен

# САКЛАУЧЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Алтынчы бүлектә геройлар үзләренең зур көчкә ия булуларын аңлыйлар.



Яр читенә килеп җиткәч, Золым белән бергә, дуслар салдан төштеләр.

Сихерче, шөбһәләнеп, Зөләйха белән Романга карап торды.

— Мин сезне һәлак итәргә теләдем, ә сез мине коткардыгыз. Миңа беркем дә, беркайчан да яхшылык эшләмәде, беркем дә мине кайгыртмады, җәлләмәде.



— Ә син үзең берәр изге эш кылып кара, нәрсә булганын күрерсең, — дип елмайды Зөләйха.

— Мине коткаруыгыз өчен рәхмәт сезгә, — диде Золым, күз карашын яшереп.


кыңгырау чәчәк

Ниндидер моңарчы күрмәгән, белмәгән бер көч сихерчене күтәреп алды, һәм ул гүзәл кызга әверелде.


— Нигә сез миңа шулай карыйсыз? — дип гаҗәпләнде Золым.



— Син безгә рәхмәт әйтеп, яхшылык кылдың һәм чын гүзәлгә әвереләдең, — дип җавап бирде Зөләйха.

— Яхшылык гаҗәеп эшләр башкара ул! — дип шатланды Роман.





— Нәрсә бу? — Роман белән Зөләйха күккә карадылар.

— Саклаучы кире кайта, — дип җавап бирде гүзәл кыз.

— Бу бит Ак Барс!

— Исәнмесез, балалар, — дуслар Саклаучының тавышын ишеттеләр. — Җиңелләрдән булмаган сәяхәтегездә сез тәвәккәллек, тапкырлык күрсәттегез, ә иң мөһиме — уйларыгызның чисталыгын, йөрәкләрегездәге игелекне саклап калдыгыз. Алар сезгә явыз көчләрне җиңеп чыгарга һәм сихерне юкка чыгарырга ярдәм иттеләр.




Сез төбәк халыкларының асыл кыйммәтләрен — игелеклелекне, мәрхәмәтлелекне, ярдәмчеллекне саклаучылар. Сез бу сыйфатларыгызны гомер буе саклап калырсыз һәм безнең җирне тагын да ямьлерәк, яхшырак, яктырак итәрсез, дип ышанам.



— Ә хәзер сезгә кире кайтырга вакыт җитте! — дип елмайды гүзәл кыз һәм Роман белән Зөләйхага карта белән каләмне сузды.

Дуслар борынгы ак манара капкасы янында пәйда булдылар, анда аларны Йорт иясе каршы алды.



— Әйдәгез, балалар, мин сезгә бер нәрсә күрсәтәм, — диде ул, серле итеп.


ТАТАРСТАН

— Бу бит безнең герб! — диде Зөләйха, гаҗәпләнеп.

— Дөрес! Безнең илнең сакчысы — канатлы Ак Барс. Гербта ул намуслылык һәм уңдырышлылыкны гәүдәләндерә.

Ул — күпмилләтле республика халкының яклаучысы.

Барсның ак булуы — уй-фикерләрнең чисталыгын, кызыл кояш игелеклелекне аңлата. Канатларындагы җиде каурый Канатлы Барсның көче җирдә дә, күктә дә бердәй булуын күрсәтә.



— Туган җиребезнең никадәр бөек һәм гүзәл икәнен күрдек без, — диде Роман, — ә никадәр табигый байлыгы бар аның! Без аны тагын да көчлерәк һәм матуррак итә алабыз! Туган һәм яшәгән җиребезнең кадерен белеп саклыйк, ул — безнең уртак йортыбыз.

## ЭЧТӘЛЕК


**УРМАН ПАТШАЛЫГЫНДА**
Беренче бүлектә урманда сак һәм әдәпле булырга кирәклеге ачыклана ........7

**ТЫЛСЫМЛЫ ЧИШМӘ**
Икенче бүлектә далада яшәүче хайваннар героиларга хаталарын төзәтергә булышалар ........21

**КОМ ТОЗАГЫ ҺӘМ ЕЛГА КАРАКОШЫ КАУРЫЕ**
Өченче бүлектә героилар Ачу белән Золымны куып тоталар һәм тылсымлы җиләк ашыйлар ........33

**УТЛЫ ТОЗАКТА**
Дүртенче бүлектә героилар ерып чыга алмастай авыр хәлгә тарыйлар .....47

**ЗОЛЫМНЫҢ СЕРЕ**
Бишенче бүлектә карта һәм тылсымлы каләм сихерче кулына эләгә ........59

**САКЛАУЧЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ**
Алтынчы бүлектә героилар үзләренең зур көчкә ия булуларын аңлыйлар ........71

# Ак Барс кайда яши?

Книга издана при поддержке Комиссии при Президенте Республики Татарстан
по вопросам сохранения и развития татарского языка
и Министерства культуры Республики Татарстан

Руководитель проекта
**Азат Ганиев**

Автор
**Гульнара Головина**

Перевод
**Клары Авхадиевой**

Литературная редакция:
**Румия Юналеева, Алсу Низамеева, Гюльнара Фазлиахметова, Ольга Афанасьева, Фансия Сафина, Инна Макарова, Фарида Ахметзянова, Зухра Фасхиева**

Художники-иллюстраторы:
**Дарья Митрофанова, Аида Ромашова, Анна Гаранина, Наталья Кочергина, Ленар Нуриев, Альфия Сабирова, Мария Елизарова, Светлана Масальских, Тамара Гурская, Фёдор Соболев, Арина Карпова, Анна Максимова, Альфия Хусаинова, Татьяна Винникова**

Музыкальная редакция
**Мария Сергеева, Рафаэль Бахтиозин, Максим Морозов**

Компьютерная вёрстка
**Дмитрия Гиацинтова**

Руководитель IT отдела
**Дамир Бариев**

Руководитель группы разработчиков приложений на Unity, 3D моделлеров и аниматоров
**Айнур Камальтдинов**

Технический директор
**Ильдар Низаметдинов**

Методисты:
**Эльмира Тахавиева, Лейсан Зинатуллина, Татьяна Курамшина**


Консультанты:
доктор биологических наук **И. И. Рахимов,**
кандидат педагогических наук **Р. Р. Шамсутдинова**

Куратор проекта
**Лейла Фазлеева**

Татарское детское издательство
420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
www.tdpress.ru

Подписано в печать 06.07.2021
Печать офсетная. Тираж 5000 экз. Заказ №
Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных
Татарским детским издательством материалов в типографии филиала
АО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идель-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

Рәсемгә кара һәм анда ике бертөрле кошчыкны тап. Үләннәр арасына ничә тычкан һәм байбак яшеренгән?







ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ

www.гдеживетбелыйбарс.рф

ТОИ ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
www.tatbook.ru

www.варислар.рф

«Татарстан Варислары» сериясенең электрон китаплары www.варислар.рф порталында урнаштырылган. Анда әлеге китапларны һәм аларга бәйле мультфильмнарны һәм мультимедиаларны йөкләтеп алу һәм карау мөмкинлеге дә бар.

Электронные книги серии «Татарстан Варислары» размещены на портале www.варислар.рф с возможностью скачивания и просмотра книг и соответствующих мультфильмов и мультимедиа.

© Татарское Детское Издательство
www.tdpress.ru

ISBN 978-5-6043753-1-0